ПРОЕКТ

**Төп гомуми белем бирү программалары буенча**
**төп дәүләт имтиханы (ТДИ) формасында**
**гомуми дәүләт йомгаклау аттестациясе**

# 2022 нче елда
# ГЕОГРАФИЯДӘН төп дәүләт имтиханын үткәрү өчен контроль үлчәү материалларының күрсәтмә варианты

«ПЕДАГОГИК ҮЛЧӘНЕШЛӘР ФЕДЕРАЛЬ ИНСТИТУТЫ»
федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе тарафыннан әзерләнде

# ГЕОГРАФИЯ буенча төп дәүләт имтиханы

## ГЕОГРАФИЯДӘН 2022 нче ел өчен төп дәүләт имтиханының контроль үлчәү материалларының демонстрацион вариантына аңлатмалар

2022 елгы имтиханның күрсәтмә варианты белән танышканда, әлеге вариантка кертелгән биремнәрнең 2022 елда КҮМ вариантлары ярдәмендә тикшереләчәк эчтәлекнең барлык элементларын да чагылдырмавын исәптә тотарга кирәк. 2022 елгы имтиханда тикшерелү ихтималы булган эчтәлек элементларының тулы исемлеге география буенча төп дәүләт имтиханын уздыру өчен укучыларның әзерлек дәрәҗәләренә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементлары кодификаторында китерелә. Сайты: www.fipi.ru

Күрсәтмә вариантта биремнәрдән конкрет мисаллар китерелә, әлеге мисаллар имтихан эше варианты биремнәренең һәр позициясендә булырга мөмкин булган барлык формулировкаларны тулаем чагылдырмый.
Имтихан вариантларын төзү өчен файдаланыла торган барлык биремнәр төп дәүләт имтиханы (ОГЭ) биремнәренең ачык банкына урнаштырылган. Сайт**: fipi.ru.**

Күрсәтмә вариант имтиханда катнашучыларның һәммәсенә һәм киң җәмәгатьчелеккә имтихан эшенең төзелеше, биремнәрнең күләме, формасы һәм аларның катлаулылык дәрәҗәсе турында күзаллау булдыру өчен тәкдим ителә.

Күрсәтмә вариантта имтихан эшенең кайбер позицияләренә берничә мисал китерелә. Имтихан эшенең реаль вариантында исә һәр позициягә бер генә бирем тәкъдим ителә.

Имтихан эшенең күрсәтмә вариантына кертелгән, киңәйтелгән җавап, таләп иткән биремнәрнең үтәлешен бәяләүнең тәкъдим ителгән критерийләре киңәйтелгән җавапны дөрес һәм тулысынча язуга куелган таләпләрне күзалларга ярдәм итәчәк.

Бу мәгълүматлар имтихан бирергә җыенучыларга 2022 елда география буенча имтиханга әзерләнүнең стратегиясен булдырырга мөмкинлек бирәчәк.

Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте 2022 ©

# ГЕОГРАФИЯ буенча 2022 нче елгы төп дәүләт имтиханында контроль үлчәү материалларының күрсәтмә (демонстрацион) варианты

## Эшне башкару буенча күрсәтмә

Имтихан эше 30 биремнән тора. Географиядән имтихан эшен башкаруга 2,5 сәгать (150 минут) вакыт бирелә.

1, 4, 5, 6, 11, 16-18 биремнәргә җаваплар дөрес җавапның номерына туры килгән бер цифр белән күрсәтелә. Бу цифрны эш текстындагы җавап кырына язып куегыз, аннан соң 1 нче номерлы бланкка күчереп языгыз.

2, 3, 7-10, 13-15, 19-27, 30 биремнәргә җаваплар сан, сүз (сүзтезмә) яки цифрлар эзлеклелеге рәвешендә күрсәтелә. Җавапны эшнең текстындагы җавап кырына язып куегыз, аннан 1 нче номерлы бланкка күчерегез. Һәр символны, бланкта китерелгән үрнәктәгечә, аерым шакмакка языгыз. Җавапны, цифрлар эзлеклелеге буларак бланкка күчергәндә (3, 8, 14, 15, 19-21, 24-26 биремнәр), өтерләрсез, буш урын калдырмыйча һәм башка төрле символлар куймыйча, бары тик шул эзлеклелектә генә күрсәтергә кирәк. Әгәр биремдәге җавапта үлчәү берәмлеге булса, җавапны бланкка күчереп язганда, бары тик исәпләп чыгарган саннарны гына язарга кирәк. Җавапта үлчәү берәмлеген күрсәтергә кирәкми.

Эштәге 23 биремгә җавап унарлы вакланма булырга мөмкин, җавапны түбәндә китерелгән үрнәк буенча эш текстының җавап кырына язып куегыз, аннан соң №1 җаваплар бланкына күчереп языгыз.

Җавап*:* *__-1,8__* мең кеше 


Эштә киңәйтелгән җавап бирү таләп ителә торган 3 бирем (12, 28 һәм 29) бар. Бу биремнәрнең җаваплары 2 нче номерлы җаваплар бланкына языла. Башта биремнең номерын, аннан соң шуңа җавап языгыз.

Эшне үтәгәндә, 7, 8 һәм 9 нчы сыйныфлар өчен географик атлас, линейка, программалаштырылмаган калькулятордан файдаланырга рөхсәт ителә.

Барлык бланклар да кара төстәге кара белән тутырыла. Гель яки капилляр ручкаларны куллану да рөхсәт ителә.

Биремнәрне үтәгәндә, караламалардан (черновиктан) файдаланырга мөмкин. **Эшне бәяләгәндә, караламадагы, һәм шулай ук контроль үлчәү материаллары текстындагы язмалар исәпкә алынмый.**

Башкарылган биремнәр өчен куелган баллар бергә кушыла. Мөмкин кадәр күбрәк биремнәрне эшләргә һәм күбрәк балл җыярга тырышыгыз.

Эшегезне тәмамлагач, һәр биремгә җавапның №1, №2 җавап бланкларына дөрес номер белән язылуын тикшереп чыгыгыз.

***Уңышлар телибез!***

Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте 2022 ©

**1** Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсы Россиядә урнашкан?

1) дөньядагы иң озын елга
2) дөньядагы иң тирән күл
3) дөньядагы иң биек тау түбәсе
4) дөньядагы иң биек шарлавык

Җавап: ☐

**2** Төшеп калдырылган урынга дәүләт атамасын языгыз.

Смоленск өлкәсе РФ чигендәге субъектларның берсе булып тора һәм РФнең _______________ белән Дәүләт чигенә чыга.

Җавап: ______________________ .

**3** Россиянең регионнарын территорияләрендә туфракның табигый уңдырышлылыгы кимү дәрәҗәсеннән чыгып урнаштырыгыз. Цифрларның килеп чыккан эзлеклелеген таблицага язып куегыз.

1) Архангельск өлкәсе
2) Смоленск өлкәсе
3) Воронеж өлкәсе

Җавап:

| | | |
|---|---|---|
| | | |

**4** Географ студентларга, тикшеренүләр уздыру өчен, Россиянең Европа өлешендә урнашкан даланың иң төньяк өлешенә барырга кирәк. Студентларга санап кителгән саклаулыкларның кайсына барырга кирәк булыр?

1) Кандалакша
2) Ока буе киртләч яры (Приокск-Террасный)
3) Таймыр
4) Әстерхан

Җавап: ☐

**ЯКИ**


Болан асраучылык, балыкчылык һәм диңгез җәнлеге промыселлары түбәндә саналып киткән кайсы халыкның традицион шөгыле булып тора?

1) карелларның
2) чукчаларның
3) мариларның
4) чуашларның

Җавап: ☐

Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте 2022 ©

***5 һәм 6 биремнәр һава торышының түбәндә китерелгән картасына нигезләнеп башкарыла.***




**5** Картада чагылыш тапкан түбәндәге шәһәрләрнең кайсының циклон хәрәкәте зонасында булуын билгеләгез?

1) Новороссийски
2) Салехард
3) Благовещенски
4) Төмән

Җавап: ☐

**6** Һава торышы картасы 27 нче апрельгә төзелгән. Картада күрсәтелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне сизелерлек дәрәҗәдә җылыту ихтималы зуррак?


1) Благовещенскида
2) Абаканда
3) Петрозаводскида
4) Элистада

Җавап:

**7** Россия Федерациясе составына кергән республиканың башкаласы булган кайсы шәһәр т.к.нең 62◦, кч.оз.-ның 34◦ географик координаталарына ия?

Җавап:______________________________.

**8** Экскурсия вакытында укучылар карьерның текә ярында тау токымнары катламнарын схема рәвешендә рәсемгә төшергәннәр:





Рәсемдә күрсәтелгән тау токымнарын яшьләре арту тәртибендә (иң яшеннән иң борынгысына кадәр) урнаштырыгыз. Цифрларның килеп чыккан эзлеклелеген таблицага язып куегыз.

1) известьташ
2) валунлы комсыл балчык
3) кварцит

Җавап:

| | | |
|---|---|---|
| | | |

***9-12 нче биремнәр түбәндәге топографик карта фрагментын кулланып эшләнә.***





**9** Картадан, туры сызык буенча, чишмәдән чиркәүгә кадәр булган араны билгеләгез. Үлчәүне нокта һәм шартлы билге үзәкләре аша башкарыгыз. Табылган нәтиҗәне дистә метрларга кадәр түгәрәкләп бирегез. Җавапны сан белән языгыз.

Җавап: ______________________ м.

**10** Карта буенча, чишмәнең манарадан кайсы юнәлештә урнашуын билгеләгез.

Җавап: ____________________ .

**11** Рәсемнәрдә, картага нигезләнеп, А – В сызыгы буенча, урын рельефының төрле укучылар тарафыннан эшләнгән профиле вариантлары күрсәтелгән. Кайсы профиль дөрес төзелгән?




Җавап: ☐

**12** Фермер җиләк-җимеш бакчасы үстерү өчен участок эзли. Аңа язын кар иртә эреп бетә, ә җәен кояш җирне иң нык җылыта торган урын кирәк. Бу участок шулай ук җыелган уңышны консерв заводына алып китү ягыннан да уңайлы булырга тиеш. Картада 1,2 һәм 3 ле цифрлар белән бирелгән участокларның кайсысы югарыдагы таләпләргә җавап бирүен ачыклагыз. Үзегезнең җавабыгызны дәлилләү өчен 2 мисал китерегез. Башта биремнең номерын күрсәтеп, җавапны 2 нче номерлы бланкка языгыз.

Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте 2022 ©

**13** Балтыйк диңгезе өске суларының уртача тозлылыгы 8 ‰. Аның 3 литр суында тозларның ничә грамм эретелүен ачыклагыз. Җавабыгызны сан белән языгыз.

Җавап: ________________________г.

**14** Кар ишелмәләре – иң куркыныч һәм хәтәр табигый күренешләрнең берсе. Түбәндә Россия регионнары санап кителә, шуларның икесендә кар ишелмәләре аеруча куркыныч тудыра. Шул регионнарны билгеләгез.Таблицага шул регионнарны чагылдырган цифрларны язып куегыз.

1) Калининград өлкәсе
2) Төньяк Осетия – Алания Республикасы
3) Әстерхан өлкәсе
4) Архангельск өлкәсе
5) Камчатка крае

Җавап:

| | |
|---|---|
| | |

**15** Кеше тарафыннан алып барылган хуҗалык эшләренең кайсы икесе калкулык битләрендә ерымнар ясалудан саклый? Кеше алып барган хуҗалык эшчәнлеген чагылдырган ике цифрны таблицага язып куегыз.

1) агачлар һәм куаклар утырту
2) терлекләр көтү
3) территорияне буйга сөрү
4) минераль ашламалар куллануны чикләү
5) тау битләрен киртләчләү (баскычлау, террасалау)

Җавап:

| | |
|---|---|
| | |

Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте 2022 ©

***16 һәм 17 нче биремнәр түбәндәге текстны кулланып эшләнә.***

Россиядәге берничә торак пунктта яшәүче укучылар үз регионнарында һава торышының җирле метеостанцияләрдән алынган күпьеллык метеокүзәтү мәгълүматлары белән алмашканнар. Аларның күзәтү нәтиҗәләре түбәндәге таблицада күрсәтелгән.

| Күзәтү пункты | Күзәтү пунктының географик координаталары | Диңгез өсте тигезлегеннән биеклеге, м | Һаваның уртача температурасы, °С | | Атмосфера явым-төшемнәренең уртача еллык күләме, мм |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | июль | гыйнвар | |
| Сортавала | 61°т.к. 30° кч.о. | 17 | +16,4 | -9,8 | 570 |
| Вологда | 59°т.к. 40° кч.о. | 125 | +17,0 | -11,9 | 568 |
| Балахна | 57°т.к. 44° кч.о. | 63 | +19,0 | -11,6 | 542 |
| Уфа | 54°т.к. 56° кч.о. | 104 | +19,5 | -15,0 | 569 |

**16** Укучылар җыелган мәгълүматларны пунктка хас климат үзенчәлекләре белән географик урыны арасындагы бәйләнешне ачыклау максатыннан анализлап чыкканнар. Төрле укучыларның нәтиҗәләре төрлечә килеп чыккан. Укучыларның кайсысы, мәгълүматларга таянып, дөрес нәтиҗә ясаган?

1) Алина: “Көньяк-көнчыгышка күчкән саен атмосфера явым-төшемнәренең уртача еллык күләме югарырак”.
2) Сергей: “Көньяк-көнчыгышка күчкән саен һава температурасының уртача еллык амплитудасы югарырык”.
3) Георгий: “Төньякка авышкан саен гыйнвар аендагы һава температурасы түбәнрәк”.
4) Тамара: “Пункт диңгез өсте тигезлегеннән югарырак урнашкан саен, июльдә анда салкынрак”.

Җавап: ☐


**17** Түбәндә бирелгән торак пунктларның кайсында 22 июньнең көн уртасында җирле сәгать вакыты буенча кояш нурлары төшү почмагы иң кечкенә булыр?


1) Сортавалада
2) Вологдада
3) Балахнада
4) Уфада

Җавап: ☐

Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте 2022 ©

**18** Климатограмманы анализлагыз һәм андагы климат характеристикасының картада кайсы хәреф белән күрсәтелгән пунктка туры килүен билгеләгез.




1) A 2) B 3) C 4) D

Җавап:

**19** Россия регионнарын анда яшәүчеләрнең Яңа елны каршы алу эзлеклелеге буенча урнаштырыгыз. Регионнар билгеләнгән цифрларны дөрес эзлеклелектә таблицага языгыз.

1) Коми республикасы
2) Омск өлкәсе
3) Хабаровск крае

Җавап:

| | | |
|---|---|---|
| | | |

**20** Россиянең төрле регионнарындагы туристлык фирмалары үз регионнарына туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап табалар. Слоганнар һәм регионнар арасында бәйлелекне билгеләгез: беренче баганадагы һәрбер элементка икенче баганадан туры килә торган элементны сайлап алыгыз.

| СЛОГАННАР | РЕГИОННАР |
|---|---|
| А) Монда иксез-чиксез күлләр, утраулар, Кивач шарлавыгы белән сокланырга мөмкин! | 1)Карелия Республикасы |
| Б) Телецк күленә – тауның матурлыкта мисалы булмаган энҗе бөртегенә – рәхим итегез! | 2) Краснодар крае |
| | 3)Алтай Республикасы |
| | 4) Самара өлкәсе |

Сайлаган цифрларны таблицага бирелгән хәрефләр астына язып куегыз.

Җавап:

| А | Б |
|---|---|
| | |

**21** Түбәндә китерелгән фикерләрнең кайсында халык саны торгызылу турында мәгълүмат булган икесен сайлап алып таблицага номерларын язып куегыз.


1) XX гасырда Россиядә эре шәһәрләрнең территорияләре, күршеләрендәге кечерәк шәһәрләр аларга кушылу нәтиҗәсендә, кызу темплар белән зурая, шәһәр агломерацияләре барлыкка килә.
2) 2019 нчы елның башында Төньяк Кавказ федераль округында халык тыгызлыгының уртача күрсәткече ил күләмендә иң югары – 1 квадрат километрга 58 кеше булган.
3) 2018 елдаРоссиянең күпчелек регионнарында халыкның табигый рәвештә кимүе күзәтелгән.
4) 2018 елда Төньяк Кавказ федераль округында туучылар саны үлүчеләр санынннан 68 453 кешегә артыграк булган.
5) 2019 елда РФ сенә башка илләрдән даими яшәү урынына 701 234 кеше килгән, РФ сеннән башка илләргә 416 131 кеше киткән.

Җавап:

| | | |
|---|---|---|
| | | |

***22 һәм 23 нче биремнәр статистик мәгълүматларны кулланып башкарыла.***

**2013-2019 елларда Россиядә халыкара миграция**




**22** Графикта китерелгән мәгълүматлар буенча, Россиягә башка илләрдән даими яшәү урынына халыкның иң күп санда күчеше ничәнче елда күзәтелә?

Җавап: ___________________________елда.

**23** 2018 елда Россия халкының миграция күләмен билгеләгез. Җавабыгызны сан белән языгыз.

Җавап: ___________________________ кеше.

**24** Россиянең түбәндә китерелгән регионнарының кайсында халык санының уртача тыгызлыгы иң югары? Әлеге регионнар бирелгән саннарны таблицага язып куегыз.

1) Камчатка крае
2) Ростов өлкәсе
3) Мурманск өлкәсе
4) Карелия Республикасы
5) Омск өлкәсе

Җавап:

| | |
|---|---|
| | |

**25** Түбәндә санап үтелгән шәһәрләрне анда яшәүче халык санының артуы тәртибендә языгыз. Барлыкка килгән цифрлар эзлеклелеген таблицага языгыз.

1) Липек
2) Новосибирск
3) Псков

Җавап:

| | | |
|---|---|---|
| | | |

**26** Түбәндә китерелгән шәһәрләрдән алюминий сәнәгате үзәге булган ике шәһәрне билгеләгез. Шул шәһәрләр бирелгән цифрларны таблицага язып куегыз.

1) Красноярск
2) Ярославль
3) Петрозаводск
4) Череповец
5) Братск

Җавап:

| | |
|---|---|
| | |

**ЯКИ**

Түбәндә кителегән халыкларның икесе Төньяк Кавказның төп халкы булып тора, шуларны билгеләгез, туры килгән цифрларын таблицага язып куегыз.

1) бурятлар
2) марилар
3) карачайлар
4) осетиннар
5) тувалылар

Җавап:

| | |
|---|---|
| | |

Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте 2022 ©

***27 - 29 нче биремнәр түбәндәге тексттан файдаланып эшләнә.***

**Зөя ГЭСы**

Зөя ГЭСы Ерак Көнчыгыштагы Зөя елгасында урнашкан. Станциянең егәре 1330 МВт. ГЭСны төзү турындагы карар әле 1964 нче елда кабул ителә. 1980 елда станция проектта күрсәтелгән 1290 МВт егәрлеккә чыгарыла. Шул ук вакытта Зөя сусаклагычы да проектта күрсәтелгән дәрәҗәгә җиткерелеп тутырыла. Регионда ел саен җәй азагы – көз башында, аерым елларда сусаклагычның тулып ташуына китерә торган көчле яңгырлар була, нәтиҗәдә суны файдасызга агызырга туры килә. Бу кайвакыт елга агымының түбән өлешендәге территорияләрне су басуга китерә. Суны иң күп күләмдә агызу 2007нче һәм 2013 нче елларда күзәтелә.

**27** Текстта телгә алынган, ГЭС төзелгән Зөя елгасы кайсы елганың кушылдыгы булып тора?

Җавап: ___________________________.

**28** Текстта телгә алынган предприятие тармакара комплексларның кайсына карый?

Җавабыгызны, башта биремнең номерын язып, 2нче номерлы җаваплар бланкына языгыз.

**29** Текстта бирелгәнчә, регионда ел саен җәй азагы – көз башында күзәтелгән, аерым елларда Зөя сусаклагычыннан суны агызу ихтыяҗы китереп чыгара торган көчле явым-төшемнәр явуның нәрсә белән бәйләнгән булуын аңлатыгыз.

Җавабыгызны, башта биремнең номерын язып, 2 нче номерлы җаваплар бланкына языгыз.

**30** Кыскача тасвирламадан чыгып, Россиянең кайсы регионы булуын билгеләгез.

Бу өлкә илнең Европа өлешендә урнашкан һәм чит илләр белән чиктәш. Территориясенең күпчелек өлеше поляр түгәрәк аръягында урнашкан. Аның территориясендә тимер рудасы һәм төсле металл рудалары булу зур әһәмияткә ия. Өлкәнең территориясендә эре АЭС эшли.

Җавап: ____________________ өлкәсе.

***Һәр җавабыгызның үз биреме янәшәсендә язылуын кабат тикшереп чыгыгыз.***


## География буенча имтихан эшен бәяләү системасы

1-11, 13-27, 30 нчы биремнәр дөрес эшләнсә, 1 балл куела. Әгәр таләпителгән бер-ике сүз, сан, цифр яки цифрлар эзлеклелеге дөрес күрсәтелсә, бирем дөрес эшләнгән дип санала.

<table>
<tr><th>Биремнең номеры</th><th>Дөрес җавап</th></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td></tr>
<tr><td>2</td><td>Белоруссия яки Беларусь</td></tr>
<tr><td>3</td><td>321</td></tr>
<tr><td>4</td><td>2 | 2</td></tr>
<tr><td>5</td><td>3</td></tr>
<tr><td>6</td><td>1</td></tr>
<tr><td>7</td><td>Петрозаводск</td></tr>
<tr><td>8</td><td>213</td></tr>
<tr><td>9</td><td>400<яки>410<яки >420<яки > 430 < яки>440</td></tr>
<tr><td>10</td><td>С< яки> Төньяк< яки> төньякта</td></tr>
<tr><td>11</td><td>4</td></tr>
<tr><td>13</td><td>24</td></tr>
<tr><td>14</td><td>25< яки >52</td></tr>
<tr><td>15</td><td>15< яки >51</td></tr>
<tr><td>16</td><td>2</td></tr>
<tr><td>17</td><td>1</td></tr>
<tr><td>18</td><td>2</td></tr>
<tr><td>19</td><td>321</td></tr>
<tr><td>20</td><td>13</td></tr>
<tr><td>21</td><td>34< яки >43</td></tr>
<tr><td>22</td><td>2019</td></tr>
<tr><td>23</td><td>124 854</td></tr>
<tr><td>24</td><td>25< яки >52</td></tr>
<tr><td>25</td><td>312</td></tr>
<tr><td>26</td><td>15< яки >51 | 34< яки >43</td></tr>
<tr><td>27</td><td>Амур</td></tr>
<tr><td>30</td><td>Мурманск</td></tr>
</table>

Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте 2022 ©

## Киң җавап белән эшләнгән биремнәрне бәяләү критерийләре




**12** Фермер җиләк-җимеш бакчасы үстерү өчен участок эзли. Аңа язын кар иртә эреп бетә, ә җәен кояш җирне иң нык җылыта торган урын кирәк. Бу участок шулай ук җыелган уңышны консерв заводына алып китү ягыннан да уңайлы булырга тиеш. Картада 1,2 һәм 3 ле цифрлар белән бирелгән участокларның кайсысы югарыдагы таләпләргә җавап бирүен ачыклагыз. Үзегезнең җавабыгызны дәлилләү өчен 2 мисал китерегез.

Башта биремнең номерын күрсәтеп, җавапны 2 нче номерлы бланкка языгыз.

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм аны бәяләү буенча күрсәтмәләр**<br>(җавапның, эчтәлегенә хилафлык китерми торган, башка төрле формулировкалары да бирелергә мөмкин) | **Баллар** |
|---|---|
| Җавапта күрсәтелгән таләпләргә барысыннан да күбрәк җавап бирә торган участок булып<br><br>1) 2 нче участок тора.<br>Нигезләмәдә түбәндәге дәлилләр китерелә:<br>2) кишәрлек шоссега башкаларга караганда якынрак урнашкан;<br>3) кишәрлек көньяк экспозициянең сөзәклегендә урнашкан. | |
| Җавап югарыда күрсәтелгән өч элементны да үз эченә алган | 2 |
| Җавап югарыда күрсәтелгән ике элементны (1 нче һәм 2 нче яки 1 нче һәм 3 нче ) үз эченә алган.<br><br>ЯКИ Җавапта 1 нче элемент чагылыш тапмаган, ләкин таләпләргә иң нык җавап биргән участокның 1 участок булуы турында әйтелә **һәм** нигезләмәдә 2 нче элемент китерелә.<br><br>ЯКИ Җавапта 1 нче элемент чагылыш тапмый, ләкин таләпләргә иң нык җавап биргән кишәрлекнең 3 нче кишәрлек булуы күрсәтелә **һәм** нигезләмәдә 3 нче элемент китерелә.<br><br>ЯКИ Җавапта 1 нче элемент чагылыш тапмый, ләкин анда сөзәклек экспозициясе һәм картада чагылыш тапкан һәр өч кишәрлекнең шоссега карата урнашуы дөрес күрсәтелгән | 1 |
| Билгеләрне 1 һәм 2 балл белән бәяләп куюның югарыда китерелгән критерийләренә җавап бирми торган барлык җаваплар | 0 |
| *Максималь балл* | *2* |

**Зөя ГЭСы**

Зөя ГЭСы Ерак Көнчыгыштагы Зөя елгасында урнашкан. Станциянең егәре 1330 МВт. ГЭСны төзү турындагы карар әле 1964 нче елда кабул ителә. 1980 елда станция проектта күрсәтелгән 1290 МВт егәрлеккә чыгарыла. Шул ук вакытта Зәй сусаклагычы да проектта күрсәтелгән дәрәҗәгә җиткерелеп тутырыла. Регионда ел саен җәй азагы – көз башында, аерым елларда сусаклагычның тулып ташуына китерә торган көчле яңгырлар була, нәтиҗәдә суны файдасызга агызырга туры килә. Бу кайвакыт елга агымының түбән өлешендәге территорияләрне су басуга китерә. Суны иң күп күләмдә агызу 2007 нче һәм 2013 нче елларда күзәтелә.

**28** Текстта телгә алынган предприятие тармакара комплексларның кайсына карый?
Җавабыгызны, башта биремнең номерын язып, 2 нче номерлы җаваплар бланкына языгыз.

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалар бирелергә мөмкин) | **Баллар** |
|---|---|
| Җавапта ягулык –энергетика комплексы (ГЭК) турында сөйләнә | |
| Җавапта югарыда китерелгән элемент бар | 1 |
| Югарыдагы билге кую критерийларына туры килмәгән барлык җаваплар 1 балл белән бәяләнә | 0 |
| *Максималь балл* | *1* |

**29** Регионда һәр елны җәй азагы – көз башында күзәтелә, Зөя сусаклагычыннан периодик рәвештә суны файдасызга агызу ихтыяҗы тудыра торган мул явым-төшемнәрнең нәрсәгә бәйле булуын аңлатыгыз.
Җавабыгызны, башта биремнең номерын язып, 2 нче номерлы җаваплар бланкына языгыз.

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалар бирелергә мөмкин) | **Баллар** |
|---|---|
| Җавапта Тын океаннан дымлы һава массалары алып килә торган муссоннар турында сөйләнә.<br>ЯКИ актив циклон эшчәнлеге турында | |
| Җавапта югарыда китерелгән элемент бар | 1 |
| Югарыдагы билге кую критерийларына туры килмәгән барлык җаваплар 1 балл белән бәяләнә | 0 |
| *Максималь балл* | *1* |

Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте 2022 ©

Төп гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясе үткәрү тәртибе нигезендә (Россия мәгариф министрлыгы һәм мәгарифкә күзәтчелек итүнең (обрнадзорның) Россия юстиция министрлыгы тарафыннан 10.12.2018 ел, 52953 нче номер белән теркәлгән 07.11.2018 елгы 189/1513 нче номерлы боерыгы)

"64. Имтихан эше ике эксперт тарафыннан тикшерелә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча экспертлар бер-берсенә бәйсез рәвештә имтихан эше биременең һәр җавабы өчен баллар куялар. Ике эксперт тарафыннан куелган балларның аермасы зур булган очракта өченче тикшерү билгеләнә. Баллардагы күзгә бәрелеп торырлык аерма уку предметының бәяләү критерийларында билгеләнгән.

Өченче экспертны, элек имтихан эшләрен тикшермәгән экспертлар арасыннан, предмет комиссиясе председателе билгели.

Өченче экспертка укучының имтихан эшен тикшергән экспертлар тарафыннан куелган баллар турында мәгълүмат бирелә. Өченче эксперт тарафыннан куелган баллар соңгы балл булып санала".

Ике эксперт тарафыннан 12 биремне үтәгән өчен куелган балларда аерма 2 булганда, бу аерма зур санала. Өченче эксперт бәяләүдә зур аерма булган 12 нче биремнең җавапларын гына тикшерә.

Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте 2022 ©